| Республика Татарстан<br>**СОВЕТ**<br>**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | Татарстан Республикасы<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ**<br>**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ**<br>**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.07.2021 №14

“Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 20021 елның 19 мартындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының кәтелгән үтәлеше нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2020 елның 4 гыйнварындагы 3-ПР номерлы уртак коллегиясе беркетмәсен исәпкә алып

1.Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 19 мартындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3.3.8 пункт өстәргә:

«3.3.8. Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турындагы белешмәләр аварияле хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнми).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль

районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл жирлеге
Советы Рәисе

А.Н.Габдрахманов